КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 8 апрель г.Казань № 371

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчеләрнең инвалидларны, шул исәптән махсус хәрби операция инвалидлары – ветераннарын эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карары белән расланган Эш бирүчеләрнең инвалидларны, шул исәптән махсус хәрби операция инвалидлары – ветераннарын эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчеләрнең инвалидларны, шул исәптән махсус хәрби операция инвалидлары – ветераннарын эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 декабрь, 1141 нче; 2020 ел, 13 июль, 584 нче; 2021 ел, 31 май, 408 нче; 2022 ел, 11 февраль, 114 нче; 2022 ел, 10 июнь, 546 нчы; 2022 ел, 16 декабрь, 1354 нче; 2023 ел, 2 май, 549 нчы; 2023 ел, 30 май, 660 нчы; 2023 ел, 22 сентябрь, 1180 нче; 2024 ел, 6 август, 626 нчы; 2024 ел, 27 сентябрь, 839 нчы; 2024 ел, 28 декабрь,

1245 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Эш бирүчеләрнең инвалидларны, шул исәптән махсус хәрби операция инвалидлары – ветераннарын эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктның икенче абзацында татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

5.6 пунктның беренче абзацында «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.2 пунктның беренче абзацында татар текстында «Субсидия» сүзен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

7.3 пунктта:

8.6 пунктта «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта татар текстында «субсидияне кире кайтару көненә» сүзләрен «субсидияне (субсидиянең бер өлешен) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару көненә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин